УКАЗ
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
УКАЗЫ

Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау һәм янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә дәүләт идарәсен оештыру һәм координацияләү чаралары турында» 2007 елның 8 сентябрендәге ПУ-511 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-204 номерлы, 2009 елның 5 сентябрендәге ПУ-482 номерлы, 2011 елның 22 апрелендәге ПУ-235 номерлы, 2012 елның 11 июлендәге ПУ-457 номерлы, 2013 елның 7 мартындагы ПУ-208 номерлы, 2013 елның 6 августындагы ПУ-716 номерлы, 2013 елның 9 октябрендәге ПУ-1007 номерлы, 2014 елның 22 февралендәге ПУ-198 номерлы, 2015 елның 19 мартындагы ПУ-298 номерлы, 2015 елның 14 ноябрендәге ПУ-1094 номерлы, 2016 елның 3 февралендәге ПУ-76 номерлы, 2016 елның 12 декабрендәге ПУ-1092 номерлы, 2017 елның 16 июнендәге ПУ-507 номерлы, 2018 елның 19 апрелендәге ПУ-325 номерлы, 2019 елның 19 мартындагы ПУ-174 номерлы, 2019 елның 11 апрелендәге ПУ-216 номерлы, 2019 елның 10 сентябрендәге ПУ-531 номерлы, 2020 елның 10 февралендәге ПУ-73 номерлы, 2021 елның 26 августындагы ПУ-675 номерлы, 2021 елның 12 ноябрендәге ПУ-871 номерлы указлары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 10 маендагы 286 номерлы, 2024 елның 5 сентябрендәге 688 номерлы һәм 2025 елның 6 июнендәге 449 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан И.В. Волынецны, М.М. Миңнуллинны, Ф.У. Мөхәммәтҗановны, А.Р. Хәйруллинны, А.В. Шадриковны чыгарырга;

б) Комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Абашев Альмир Рәшит улын – Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрын;

Захарова Светлана Михайловнаны – Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне (килешү буенча);

Җиһаншин Азат Илдус улын – Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министрын;

Начвин Илья Сергеевичны – Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрын;

Соколов Алексей Владимировичны – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры урынбасары – полиция башлыгын (килешү буенча).

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2026 ел, 14 март
№ 203